ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“4” май 2017 ел** **№6**

**Түбән Мәтәскә авылында «Арчабаш" торак массивы территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Уставы, Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2009 елның 19 октябрендәге 85 номерлы карары белән расланган Иске Кырлай авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 5 маендагы 5 номерлы карары белән расланган Түбән Мәтәскә авылында «Арчабаш» торак массивы территориясен планлаштыру проекты һәм межалау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты-12.06.2017 ел, 10.00;

2.2. Үткәрү урыны-Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасы;

2.3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр тапшыру, чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү адресы: ТР, Арча районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай урамы, 2 йорт (эш көннәрендә – 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты-11.06.2017 елга кадәр (тел. 56-2-93).

3. Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлауларны әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән

тәртип һәм карар белән билгеләнгән срокларда күрсәтелгән әлеге мәсьәлә буенча әзерләргә һәм үткәрергә.

4. 2017 елның 12 маена кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru)һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф. Г. Сираҗетдинов